Татарстан яшьләре

№ 35

(8757)

СИШӘМБЕ

23 март, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Президент Рамазан белән котлады

Үткән атна җомгасында Президент М.Шәймиев Мәрҗани һәм Әҗем мәчетләрендә булды. Башка дәүләт җитәкчеләренең зур дини бәйрәмнәрдә чиркәү яки мәчеткә баруы гадәти хәлгә әверелгән чорда, бу әллә ни зур вакыйгага да түгел кебек. Ләкин үз Президентыңның акрынлап булса да башкалар кебек була баруын күрү күңелле. Димәк, дин дәүләттән аерылган дигән кире кагулар урынына килешү, кешечә мөнәсәбәтләрне торгызырга тырышу килә. Әхлаклылык, тәртип кебек төшенчәләр һәркайсыбыз өчен зарури булган заманда Президентның мәчеткә килүе күңелдә өмет чаткысы уята. Без барыбыз да кешеләр бит!

Ельцин Мәскәүне аякка бастырды

"Т.Я." 32 санында Борис Ельцинның Русия халык депутатларының YIII съездында җиңелүен һәм якын араларда халыкка мөрәҗәгать итәчәге турында язган иде. Сәясәт белән әзме-күпме кызыксынучылар атна буе президентның чыгышын көтте, ә аның матбугат сәркатибе В.Костиков җәмәгатьчелекне котырткалап торды. Янәсе, Ельцин инде ныклы карарга килде һәм тиздән үз сүзен әйтәчәк. Моны ишетеп Вашингтоннан Конституция Суды рәисе В.Зорькин кайтып төште.

Ниһаять, шимбә көнне, 21 сәгать 30 минутта телевизор экранында съезддан соң тавыш-тыны чыкмаган Ельцин пәйда булды. Ул үзенең чираттагы фәрманга кул куюын әйтте һәм аның эчтәлеге белән таныштырды. Президент идарә итүнең махсус тәртибе урнаштырылуы турында хәбәр итте. Бу махсус тәртип, ә төгәлрәк итеп әйтсәң, Президент идарәсе, Ельцин әйтүенчә хакимият кризисы тәмамланганчы дәвам итәчәк. 1993 елның 25 апрелендә тавыш бирү, ягъни референдум уздырылачак. Анда сайлаучылар Русиянең президенты һәм вице-президентына ышаналармы, юкмы икәннәрен белдерәчәкләр. Моның белән беррәттән Конституциянең төп положениеләре дә халык хөкеменә чыгарыла. Ельцин әйтүенчә, армия сәясәткә катнашмаячак, Федератив килешү үз көчендә калачак, Федерация субъектларының хокукларын кысу турында сүз дә булу мөмкин түгел. Ә иң мөһиме шунда ки, Ельцин үзенең эшләренә каршы килгән ЮС һәм съезд карарларын гамәлдә түгел дип белдерде, ә бу исә ЮС һәм съезд нуль дигән сүз.

Шуннан соң башланды инде мәхшәр!

Руслан Хасбулатов БДБ илләре парламентлары белән очрашуларын өзеп Мәскәүгә кайтты. Ельцинның мөрәҗәгате тәмамланып бер сәгать тә үтмәде, телевизор экранында генераль прокурор Степанков, Конституция суды рәисе Зорькин, ЮС Рәисе урынбасары Воронин, вице-президент Руцкой пәйда булдылар. Гади кешегә аларның сүзләреннән ни дә булса аңлау бик авыр булгандыр. Ләкин шунысы ачык Степанковтан кала барысы да Ельцинга оппозициягә бастылар. Шушы ук состав төн уртасында матбугат конференциясе үткәрде. Якшәмбе көнне Русия ЮС сессиягә җыелды һәм карар кабул итте. Карарда президент Конституцияне бозды дип белдерелә һәм чит ил җитәкчеләренә Русиянең эчке эшләренә тыкшынмаска тиеш булулары турында әйтелә.

Кыскасы, Ельцин үзенең мөрәҗәгате белән барысын да аякка бастырды һәм юкка да чыкты. Ә Мәскәү урамнарыннан митинглар дулкыны узды.

Ельцинның үз чыгышын шулай озакка сузуында берәр хикмәт бардыр, күрәсең. Бу чыгышның яхшылап уйланылган булуы, Ельцинның киләсе көннәрдә ниләр эшләячәген белүе көн кебек ачык. Тагын шунысы да бик мөһим, теләсә кайсы вакытта һәм теләсә кайсы илдә хакимият кризисыннан бер генә юл белән чыкканнар. Ул да булса - хакимият башына диктатор килгән. Мисаллар буа буарлык: Наполеон, Пиночет, Ленин, мәсәлән. Русия башына кем килер? Бу сорауга җавап үзен көттермәс кебек.

Рәвия САБЫР.

Татарстан боксчылары җиңелергә өйрәнмәгән

Өченче ел рәттән Дербышки поселогының Спорт йортында дөнья чемпионы Айрат Кәматов исемендәге приз өчен ярышлар үткәрелә. Быелгылары 18-21 мартларда үтте. Анда Ульян, Чабаксар, Ижау, Глазов шәһәрләре һәм Татарстан спортчылары катнашты. Украина, Беларусь һәм Эстония боксчылары акча булмау сәбәпле турнирга килә алмадылар.

Ярыш зурлар һәм яшьләр (1975-76 елда туганнар) арасында узды. Тренерлар спортчыларның әзерлекләрен тикшерделәр. Шунысы куанычлы: бөтен авырлык категорияләрендә дә Татарстан боксчылары җиңү яулады.

Ярышларны үткәрү өчен Казан оптика-механика заводы профкомы, Татарстан Республикасының Спорт буенча дәүләт комитеты, "Татмехнабор" берләшмәсе, Татар арадашчылык коммерция фирмасы зур тырышлык куйдылар.





Узган атнада Яшьләр үзәге ресторанында пешекчеләр конкурсы үткәрелде. Республикабызның яшь пешекчеләре әзерләгән тәмле, матур сый-нигъмәтләрдән күзләр камашырлык, телеңне йотарлык. Юк кына нәрсәләрдән дә кәнфит ясау шушы буладыр инде ул. Пешекчеләр искергән икмәктән генә дә нинди генә тортлар, кекслар пешермәгәннәр! Их, гел шушы конкурста катнашу хокукы алган пешекчеләр әзерләгән тәм-томнарны гына ашасаң иде!

Рәсемнәрдә: Яшьләр үзәге ресторанында үткәрелгән пешекчеләр конкурсыннан күренешләр.

Е.КАНАЕВ фотолары.

КАЙЧАН? КАЙДА? НӘРСӘ?

Парламент җитәкчесе әдәбият аксакаллары Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники белән очрашты. 92 яшьлек Гомәр аганың хәлен спикер хастаханәдә белешсә, Әмирхан аганы ул өенә барып туган көне белән котлады. Әңгәмә барышында халык язучылары Татарстандагы сәяси, икътисадый хәл турында сөйләштеләр, әдәбият һәм сәнгатьне күз уңыннан ычкындырмауларын, милли мәдәниятне торгызу эшендә әзлекле хезмәтләре өчен җитәкчелеккә рәхмәт белдерделәр.

Бүген Казанга Мәскәү һәм чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларыннан торган бер төркем кунак килергә тиеш. Моңарчы бүрәнә аша бүре куу белән шөгыльләнгән каләмдәшләребез республикадагы сәяси һәм икътисадый хәлне үз күзләре белән күреп, капшап карап өйрәнәчәкләр. Аерым алганда, алар Казан компрессорлар заводында, Түбән Кама "Нефтехим" берләшмәсендә, "КамАЗ" акционерлык җәмгыятендә, "Бәреле" совхозында булачаклар, республика халкы белән очрашачаклар. Журналистлар белән Президент М.Шәймиев тә очрашыр кебек. Бәлки, шушы хәлләрдән соң дөнья җәмәгатьчелеге Татарстан Республикасы турында дөрес мәгълүмат алыр.

1 апрельдән бәяләр "ирекkә чыгарыла" дигән фараз дөрес булмас кебек. Бәяләр Русия дәүләтендәге бәяләргә генә якынлаштырылачак.

Сессиядә каралачак проект кабул ителә калса, 1 апрельдән Татарстандагы минималь хезмәт хакы 4500 сум тәшкил итәчәк. Бу исә бюджеттагы оешма хезмәткәрләренең эш хакы да ике мәртәбә арта дигән сүз.

Кибетләрдәге яз галәмәтләре турында искәрткән идек инде. Тагын бер мәртәбә исегезгә төшерәбез: хөкүмәт килешүе нигезендә кайтарылган әфлисунның килограммы 350, хәлвәнеке - 800, зәйтүн маеныкы (1 литры) - 1900, соя маеныкы (1 литры) - 900, алманыкы - 200, сарымсакныкы 300 сум тәшкил итә. Артыграк бәяләргә сатарга тырышучы кибетчеләрнең хаксыз икәнлеген алдан ук белеп торыгыз.

Геометрия кануны яки БТИҮгә яңа җитәкче килде

Узган атнада 2 көн дәвамында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең (БТИҮ) III корылтае булып узды.

Театр бинасының зур залы татар диаспорасының БДБ илләреннән килгән күпсанлы вәкилләре янына Америка, Япония, Кытай, Төркия кебек чит дәүләтләрнең күзәтүчеләрен дә сыендырды ул көнне. Корылтайда каралачак төп мәсьәләләрнең берсе БТИҮнең платформасын билгеләү һәм аның җитәкчесен сайлау иде.

Корылтайның беренче көнендә Татарстан республикасы гражданнарының хәрби хезмәте, качаклар һәм күчеп кайтучыларның хокукларын яклау, Татарстанда Дәүләт иминлеге комитетын бетерү, республикадан читтә яшәүче милләттәшләребезгә Татарстан гражданлыгын бирү, хосусыйлаштыру, җир турындагы һәм башка кайбер проблемалар каралды.

Икенче көннә - оештыру мәсьәләсе каралды. Корылтай эшен башлауга ук Кама аръягы регионыннан килгән вәкилләр үзләренең мөрәҗәгатьләре белән чыктылар. Анда БТИҮнең президенты итеп Чаллы татар иҗтимагый үзәгендә рәистәш булган Зиннур Әһлиуллинны сайлау турында әйтелде. Чаллыдагы милли хәрәкәтнең иң көчле активистларыннан саналган, Татарстанда Русия президентын сайлауларга протест йөзеннән ачлык игълан иткән бу егетнең БТИҮнең лидеры булып алгач аны нинди юлдан алып барачагын фаразлау кыен түгел. Бу очракта аның кайчандыр Татарстан Президентына каршы чыгуын гына әйтү дә җитәдер.

Әмма шулай булуга да карамастан, Корылтай Зиннурны рәис итеп сайлады. "Милли хәрәкәткә бүре рухлы татарларны туплап, без күп этләрне җиңеп барабыз, һәм кайчан да булса тулы азатлыкка ирешкәнчә көрәшербез", - дип ант итүче Зиннур Әһлиуллинны БТИҮ рәисе (ә президенты түгел) итеп күрү кайберәүләрне шикләндерергә дә мөмкин. Моңарчы үзәккә якын торуны хуп күргән БТИҮнең алга таба читкә тайпылуы рәсми органнарны сәясәттә күпчелекне тәшкил иткән либераль көчләрне, Президентны да үзгәрергә мәҗбүр итәчәк. Чөнки геометрия законнары буенча үзәк нәкъ менә ике яктан да бер үк ераклыкта торуны таләп итә.

Журналист буласың килсә

Сезнең алда тормыш казанының иң кайнар җирендә кайнарга теләк белдергән яшьләрнең беренче язмалары. Шаккатырырлык берни дә юк кебек аларда: гадәти, кабатланган темалар, гап-гади хәлләр. Ләкин нәкъ менә шушы гадәтилекләре белән җәлеп итә алар күңелне. Бу язмаларның самимилеген дә күрми калмас укучы.

Ә бәйге дәвам итә. Дөньяга үз күзе белән карый белгән, шуны кәгазьгә төшереп җибәргән укучыларның язмалары газетада алга таба да бирелеп барылачак. Исегезгә төшерәбез: беренче өч урынны алган авторлар Казан дәүләт университетының журналистика факультетына имтихансыз кабул ителәчәк.

Бигештә урамнар тын

Газетадан "Дөньяда иң абруйлы һөнәр - журналист. Ул Президентлар белән дә, хәерчеләр белән дә аралаша. Әгәр шушы тормыш казанының иң кайнар җирендә кайнарга теләсәң, "Татарстан яшьләре" сиңа булыша ала" дигән сүзләрне уку белән сәгатьләр буе ничек бу конкурста катнашырга дип уйга батып утырдым. Ашау качты, йокы кермәде.

Минем хыялымда бар иде журналист булу теләге. Аннан соң ул, нишләптер, сүрелде. Менә бүген ул яңадан уянган кебек булды һәм шушы кайнар казанга төшәсе килә башлады.

Бүген дә кич булды. Сәгать алтылар тирәсе. Ярый, мин урамга чыгыйм әле.

Бигеш авылы. Урамда кич белән жылытып җибәргән. Аз гына җилле буран. Баганаларда утлар яна. Кешеләр инде эштән кайттылар. Җылы өйләрендә бергәләп ял итәләр. Урам тынып калган. Ара-тирә кинога баручы яшьләр генә үткәләп китә.

Менә минем каршыга бер пар килә. Болар - Энҗе апа белән Алмаз абый Гыйләҗевләр. Җырлар иҗат итүче Алмаз абый шушы инде. Саф һава суларга чыкканнар. Икесе дә, пенсиядә булуларына карамастан, эшлиләр әле. Алмаз абый - участок врачы, Энҗе апа урта мәктәптә укыта. Авыл халкы аларны бик ярата, хөрмәт итә.

Менә алар минем янымa ук килеп җиттеләр.

- Исәнмесез! Бүген урамда сез генә бугай.

- Юк, - диләр болар, - без генә түгел. Әнә теге урамнан Фәүҗәт белән Нәзилә килә. Фәүҗәт яктыртты инде бу урамнарны. Мондый якты урамга еешрак та чыгарбыз әле.

- Алмаз абый! Бүген кәефегез яхшы бугай. 1993 ел сезгә шушы урам кебек якты булырмы, әллә башкачаракмы?

- Бу ел шушы урам кебек якты булса, яхшы инде ул анысы. Яңа килгән ел җиңелрәк булсын иде. Хастаханәгә яңа җиһазлар кайтарылса, балалар үзләренең әниләрен, әбиләрен ташламасалар, нинди күңелле булыр иде. Югыйсә, безнең хастаханә картлар йортына әйләнеп бара бит. Колхоз да ныграк ярдәм итсен иде, профсоюз оешмасы авырулар хәлен еешрак белсен иде. Нишләп әле, Фәнис энем, мине сораштырасың?

- Мин болай гына. Катлаулы, авыр тормышка эчем поша. Аннары бу сорашуның сере бар. Анысын алга таба белерсез. Бәхетем булса, - дип хәйләләп алдым мин.

- Энҗе апа! Сезнең күз алдыгызга ничек килә 1993 ел?

- Бары тик яхшы булып кына, апаем. Бу ел үткән елга караганда тынычрак үтсен, кешеләр мәрхәмәтлерәк булсыннар иде.

- Мәрхәмәтле булуны сез ничек аңлыйсыз?

- Кеше бер-берсен ихтирам итә, бер-берсенә ярдәмле икән, әти-әнисенә яхшы булса, шулдыр инде мәрхәмәтлелек.

- Ярый. Сезне урам уртасында озак тоту килешмәс. Мин теге очка барып кайтам әле. Тыныч йокы сезгә.

Әнә, Фәүҗәтләр дә минем якка борылдылар.

- Исәнмесез! Нинди кызык бар? Нигә көләсез? Үзең яктырткан урамнан йөрү күңелледер инде, Фәүҗәт?

- Әйе. Урамнар якты. Тик менә лампочкалар табуы кыен. Кая барсаң да бартер. Мә сиңа да, бир миңа.

- Шулай инде, Фәүҗәт. Замананар авыр хәзер. Колхозларга бигрәк тә авырга туры килә. Хәлле колхозлар гына тернәкләнә алыр бу заманда.

- Нәзилә, синең эшләр ничек бара?

- Мин бухгалтер кешенең кәгазь арасы инде. Иртән кереп чумам, кич чыгам. Бәяләр дә көн саен үзгәреп тора.

Хушлашырга да өлгермәдек, тагын берәү килеп чыкты.

- Раиф абый! Син тормышны яхшырыр дип уйлыйсыңмы?

- Әй, энем, кеше гел яхшы булыр дип өметләнә инде ул. Аннары, барыбыз бергә тырышсак, нигә яхшырмасын ди. Бергәләп эшләргә генә кирәк. Менә без тормыш авыр дип тормыйбыз - йорт җиткерергә йөрибез. Бик авыр булса да, материалларын да табабыз. Колхоз күбрәк булышсамы...

- Ваучерларыгызны кая куярга уйлыйсыз?

- Аптыраган инде, энем. Алар белән нишләргә дә белгән юк. Файдалы әйбер булырмы инде? Әле анысы вакыт бар, ныклап уйларга кирәк.

- Безнең дә шул килеш әле, абый. Акция сатып алырбыз инде. Ярый, Раиф абый, мин кайтуга таба китәм әле. Ельцин сөйли бугай бүген. Кайтып тыңлыйм әле. Тагын ниләр вәгъдә итәр. Хәзер безнең үз Президентыбыз инде. Тик шулай да...

Фәнис НУРЕТДИНОВ.
Зәй районы,
Бигеш авылы.

Төлке өне

Кояшлы җәй көннәре җиттеме, Илсөярнең балалар бакчасына барасы килми. Барса да, төшке йокыдан соң кайчан килеп алырлар, икән дип йөри. Ял көнен һәр атнада зарыгып көтеп ала ул. Илсөяр кулъяулыгына ипи телемнәре төрә, шешәгә сөт тутыра да әтисе белән кырга китә. Әгәр йокыдан торганда әтисе өйдә булмаса, әнисенә сиздермичә генә ишек алдына чыга, кызыл башмакларын кия, аннары әтисенең трактор эзләреннән басуга йөгерә. Дерескәге, төлке балалары янына.

Эштән бушаган арада әтиле-кызлы, ипи сыныклары алып, чокыр башындагы төлке өне янына китәләр. Төлке балалары, уйнаган җирләреннән туктап, аларга карап каталар да, "фырх" итеп өяләрына кереп югалалар. Илсөяр ипи кисәкләрен сузып:

- Чыгыгыз инде, чык, ипи бирәм мин сезгә, - дип карый, ләкин елтыр күзләр юеш кара борыннарын селкетеп иснәп карыйлар да, юк инде, чыгып тормыйбыз дигәндәй, тагын да эчкәрәк кереп качалар. Илсөяр кулын да тыгып карый, ләкин тырышуы файдасыз.

"Нигә чыкмыйлар, минем төлке баласын тотып карыйсым килә", - дигән сүзләренә каршы, әтисе:

- Алар әниләрен тыңлыйлар. Димәк, әниләренең рөхсәте юк. Ипиләреңне монда калдыр да, читтән генә карап торырбыз, - дип юмалап, кызын бер якка алып китә.

Илсөяр селкенергә куркып, наяннарның ялт-йолт каранып ипи кимергәннәрен күзәтеп тора.

"Әйдә, берсен генә булса да өйгә алып кайтабыз", - дип бәйләнми ул әтисенә. Чөнки: "Туганнары бик каты елап калырлар, нишләргә белмәгән әнисе кич белән килеп, ачудан бөтен каз-тавыкларны буып китәр", - диячәк әтисе. Кырдан куян, керпе балаларын да әтисе бер генә көнгә, Илсөяргә күрсәтер өчен генә алып кайта.

- Бездә генә торсыннар инде, - дип күпме генә әйтеп караса да, әтисе һаман:

- Сорап кына алып кайттым бит аларны, әгәр дә иртәгә алып бармасам, әниләре бүтән күрсәтергә дә бирмәс, - дип кырга алып китә. Шуның өчен Илсөяргә көн саен булмаса да, кырдан "куян күчтәнәчләре" - кыпкызыл алмалар, матур пичәтле, дәү әнисе ярата торган "агәчле" кәнфитләр кайта торды.

Ләкин беркөнне килгәндә төлке өне җимерелгән, балалары юк иде. Илсөяр тораташтай катып калды. Аннары исенә килеп елап җибәрде.

- Әниләре урманга алып киткән аларны, анда тынычрак та, әйбәт тә, - дип юатты әтисе.

Кич йокларга яткач әтисе белән әнисенең пышылдап кына сөйләшкән сүзләренә колак салды кыз.

- Җир ничек күтәрә икән андый кешеләрне, өннәренә кадәр туздырып киткәннәр. Тиреләре өчен никадәр җан кыйганнар...

Төлке балаларының уйнаганнарын, түгәрәк күзләрен ялтыратып аңа карап торуларын исенә төшерде кыз.

Нишләгән бу зурлар? Ничек шулай уйнап туймас шук наяннарны үтерә алдылар икән? Керфекләре дымланды, битеннән күз яшьләре тәгәрәде Илсөярнең. Бераздан ул йокыга китте. Төшендә ул шаян төлкеләр белән бергә болында уйнап йөрде...

Гөлнар САТТАРОВА.
Кама Тамагы районы.

Яшәртәсе иде авылны!

Фаҗигале язмышка дучар ителгән кешеләр генә түгел, авыллар да бар. Мин шундый авылларның берсе - Олы Саурыш авылы турында сөйләмәкче булам. Олы Саурыш - минем туган авылым, тик авылның олы дигән исеме генә калган, хәзер инде ул бик кечкенә.

Ә булган авылның шундый вакытлары: чакрымга сузылган ике урам; йортлары бик матур, төзекләр. Тарих тәкъдире белән урамның берсендә мөселман татарлары, ә икенчесендә керәшен татарлары яшәгән. Гөр килеп торган авыл, мәчет манарасыннан мәзиннең азан әйткәне ишетелеп торса, чиркәү чаңы суккан ны да әллә кайларга яңгыраган...

Авыл халкы бик тырыш, әдәпле һәм үзара дус яшәгән. Ике диннең бәйрәмнәрен дә зурлап бәйрәм иткәннәр, бер-берсенең хәтерен калдырмаска тырышканнар.

Тегүчеләре, итекчеләре, балта осталары белән тирә-юньдә танылган булган безнең авыл.

Укымышлы кешеләрнең күп булуы белән дә данлы булган бу төбәк. Беренче Ленин ордены кавалеры Анна Ибатаеваны да бик олылап искә алалар. Ул - укытучы кеше. Ә икенче кавалер - Даут Матвеев - исән-сау яшәп, игелекле тормыш алып бара (ул орденны заманында кукуруз игү буенча алган) Атказанган зоотехник, агроном, укытучыларны саный китсәңме?..

Әйтәсе килгән фикерем шул: авыл халкы борынгыдан укымышлы, мәдәниятле һәм тырыш булган. Киләчәкне күздә тотып, балалар өчен дип яшәгәннәр, төзегәннәр безнең бабайлар бу авылны. Мәсәлән, чиркәү тавы дип атала торган калкулыкта клуб, аның белән янәшә мәктәп, медпункт һәм кибетне урнаштырганнар. Һәр кичә клубта уза торган булган, аны карарга бөтен авыл диярлек җыелган. Ял иткәннәр, бәхәсләшкәннәр, үзара фикер алышканнар.

Тәнәфестә укучылар кибеткә керсә, авыл халкы аларга юл бирер. Тизрәк алып китсеннәр, дәресләренә соңга кала күрмәсеннәр - бу авыл халкы өчен язылмаган кагыйдә булган. Нинди кече күңеллелек бит уйлап карасаң...

Миңа бу турыда әнием сөйли. Ул - укытучы. Тик болар бар да үткәннәр хатирәсе инде. Мәчет сүтелгән, чиркәү ишелгән... Халык икесенең берсен саклап кала алмаган, юньсезләргә юл куйганнардыр инде. Шуның белән авылдан ямь дә, бәрәкәт тә качкан, әлбәттә.

Моннан 20 еллар элек авыл бик матур иде әле, дип сөйли минем әнием. Сигезьеллык мәктәптә 270 бала белем ала иде, ди. Тик ни өчендер шул вакытларда авылга югарыдан "перспективасыз" дигән мөһер сугылган була. Ул чактагы җитәкчеләргә нәрсәсе беләндер ошамый авыл. Авыл көнләп, күзгә күренеп юкка чыга, тарала барган. Башта колхоз идарәсен күчерәләр, аннан авыл советын, аннан мәктәпне... Мәктәп артыннан яшь гаиләләр дә кузгала, билгеле. Ә балалары артыннан - ата-аналар... Анысы инде мин белә башлагач, минем күз алдымда эшләнде. Авыл ялгыз карт-карчыклары белән ятим, кызганыч хәлдә утырып калды. Мәктәпкә бер унлап бала керергә тиеш булсак, хәзер менә урта мәктәптә ялгызым укып йөрим.

Юк, мин, авылны ташлап киттеләр дип, кемнәдер гаепләргә җыенмыйм. Эшсез калу, юлсызлык, өметсезлек, кыскасы, шул вакыттагы сәясәт өеренә эләккәннәр алар.

Тик туган җир, туган туфрак барыбер юксындыра, сагындыра булыр. Шулай булмаса, елкәннәр үзләренә мәңгелек йортны шушы авыл зиратыннан эзләмәсләр иде. Инде бер казыгы да калмаган нигез туфрагына салкын гәүдәләрен китерүне васыять итеп әйтмәсләр иде. Менә шул вакытта үзәкләр өзелә инде, никадәр сагынып, җирсеп яшәгәнен аңлыйсың бу кешеләрнең. Хәсән Туфан юкка гына:

Торган җир - кемеш,
Туган җир - алтын,

- дип язмагандыр. Әйтәсе килгән фикерем шул: үз аягыгыз белән, кулда көч барында кайтыгыз туган якларга, якташлар!

Фәридә ГАЙНУЛЛИНА.
Тәләче районы,

Өзелде моң

(парча)

Юк инде ул хәзер. Китте. Бөтенләйгә, мәңгегә. Тик күңелдә, йөрәкнең иң түрендә, ул уйнаган көйләрнең кабатланмас моңы гына калды.

Халыкта шундый сүз бар: имеш, җыр-моң яраткан кеше кыска гомерле була. Бәлки ул алай да түгелдер. Тик менә бу сүзләр нәкъ аның турында әйтелгән кебек.

Ул да шулай җыр-моң ярата, яңа көй ишетсә, бөтен дөньясын ташлап, баянына тотына, тизрәк аны отып калырга, өйрәнергә, аңа үзеннән дә аһәң өстәргә тырыша, мең дә бер кабат уйный, үзе генә белә торган күңел көймәләренә басып бизәкли иде. Җырга, моңга, тылсымлы гитара кылларына, аның бармаклары кагылу белән моң агылырга торган гармун, баян телләренә җаны-тәне, бөтен булмышы белән гашыйк иде. Шушы илаһи музыка дөньясы аны һәрчак үзенә тартты, үзенә әсир итте, җырлаттырды да, елаттырды да, шатландырды да, кайгыртты да.

Ул мәшһүр җырчы да, атаклы гармунчы да, виртуоз гитарист та түгел иде, бер гади авыл егете булды һәм булып калды. Әмма гүзәл музыка дөньясында мәшһүр җырчылардан, атаклы баянчылардан ким йөзмәде. Уйнаган һәр көенә үзенең эчке моң дөньясыннан серле өстәмәләр куша, көйне үзенчә моңландыра, башкалар кабатлый алмаслык итеп уйный иде.

Әйе, ул моңлы да, дәртле дә, ездереп тә, оста да итеп уйный белде. Тик... гомере генә кыска булды.

Үзе китте, ә ул уйнаган көйләр, өзелгән моң булып, йөрәкнең иң түрендә мәңгегә калды.

Зәйфә СӘЛИХОВА.
Бәләбәй шәһәре.



Язмый торган журналистлар да бар

Алар - фоторепортерлар. Шуларның берсе - В.Зөфәрев җан өшеткеч җилле көндә сәгать ярым ачык һавада эшләп, авын уңышлы тәмамлаган. Зөфәревнең менә бу рәсеме 1992 ел йомгаклары буенча иң яхшы 10 рәсем исемлегенә керде.

Махсуслаштырылган җирле "Агропромышленность комплексы" инвестиция фонды

«АПК» ДУЛКЫННАРЫНДА

Туган-тумачаларыгыз, таныш-белешләрегез белән киңәшкәннән соң махсуслаштырылган җирле "Агропромышленность комплексы" инвестиция фонды акцияләрен сатып алырга карар бирдегез ди. Бу ниятегезне гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләрне белү зарури:

Беренчедән. Сезгә фондның җирле вәкиллегенә барырга кирәк. Аның адресы: Казан, Декабристлар урамы, 1 нче йорт, Идел-Кама биржасы, 2 нче кат, 11 нче бүлмә. Тел. 53-03-07.

Икенчедән. Бирегә килгәндә сезнең кесәгездә паспортыгыз, саклык кенәгәгез, ваучерларыгыз һәм акчагыз булырга тиеш. чек ваучер) плюс 180 сумга 6 акция бирелә. Бер акциянең бәясе 1500 сумга йөри.

Бүгенге көнгә фонд инде 100000 акциясен сатарга өлгергән. Ашыгa төшәргә киңәш бирәбез, ник дигәндә, 31 марттан акцияләрне сату шартлары үзгәрәчәк.

Улмы? Ул...

Шушындый баш астында без сәүдә, икътисад эшләре белән бәйле терминнарга аңлатмалар биреп барабыз. Теге яки бу сүзне тәфсирләп бирүне сорап редакциягә инде хатлар да килә башлады. "Һәркемнең үз ваучерын уңышлырак итеп файдаланасы килә, - дип яза укучыбыз Вакыйф Зәйнуллин. - Коры кәгазь тотып, төп башына утырып каласы килми. Бер карчык әйтмешли, минем кызым кияү күргәнмени дигәндәй, моңа кадәр ваучер ише нәрсәне белгән кешемени без. Күпләр тары арасыннан алтын бөртеге эзләгән әтәч сыман бизнес сүзлегендә казына хәзер. Бик кирәкле, көн кадагына суга торган эшкә алынгансыз. Рәхмәт сезгә!"

ДИВИДЕНД. Бик гади итеп әйткәндә, акция сатып алган кешегә килеп торучы табыш. Акционерлар җәмгыяте җыелган акчаны файда китерерлек эшкә тота һәм табыш алганнан соң аның бер өлешен акционерларына түли. Менә шушы акча дивиденд дип атала.

КЫЙММӘТЛЕ КӘГАЗЬЛӘР БАЗАРЫ. Моны болай аңлатырга була. Эшкуарларның яки дәүләтнең нинди дә булса файдалы һәм кирәкле эшкә тотар өчен акчасы җитми. Шунлыктан алар кыйммәтле кәгазьләр чыгаралар һәм бу кәгазьләрне халыкка сатып акча туплыйлар. Кыйммәтле кәгазьләр базарының бурычы - өлеге акчаларның тиз арада эшли башлавын тәэмин итү. Кыйммәтле кәгазьләр базарын арадашчылардан, ягъни брокер һәм дилерлардан башка күз алдына китереп булмый.

БРОКЕР. Ул сатучы белән сатып алучыны кавыштыручы. Күрсәткән хезмәте өчен ул процентлар ала.

ДИЛЕР. Сатучы белән сатып алучыны кавыштырудан тыш үзе дә кыйммәтле кәгазьләр сатып ала. Аннан аларны югарырак бәягә бүтәннәргә сата.

Брокер һәм дилерларның кереме сәүдәнең ничек баруына бәйле, шуңа күрә алар кул кушырып утырмыйлар, ә клиентларны үзләре эзләп табалар.

МАРКЕТИНГ. Инглиз сүзеннән ясалган (market - базар). Ул эшне оештыру һәм җитештерелгән продукцияне сатуның комплекслы системасы. Төп максаты - кулланучыларның ихтыяҗларын өйрәнү һәм бу ихтыяҗны тиз арада канәгатьләндерү хисабына табыш алу.




Укучыларыбызны тагын бер кат искәртәбез: "АПК" инвестиция фонды турындагы язмаларны игътибар белән укып һәм җыеп барыгыз. Алда сезне күңелле хәбәрләр көтә.

Зөлфәт ХӘКИМ

ҖЕН БУТАДЫ...

(повестьтан өзекләр)



(Дәвамы. Башы газетабызның 32-34 нче саннарында).

* * *

Саимә, өйгә кергәч, ишек катында кымшанмыйча басып торды. Өйдә бөтен нәрсәнең асты өскә килгән - шапшаклык, тәртипсезлек хөкем сөрә иде. Караватт шыгырдап куйды, юрган астыннан гырылдаган тавыш ишетелде.

- Тагын исерек бугай... - дип мыгырдады Саимә һәм өйне җыештырырга кереште. - Әй, Сәлмән... - Юрган астында гырылдау көчәйде. - Әй, Сәлмән, өйне абзарга әйләндереп бетергәнсең бит...

Шулвакыт юрган астыннан Хатыйпның ике мөгезле башы килеп чыкты.

Саимә җан өзгеч тавыш белән кычкырды да, шапылдап идәнгә ауды - бу аның һуштан язуы иде.

Җен сикереп торып тиз генә ишекне бикләде, чалбарын, күлмәген киде, койрыгын кесәсенә тыгып куйды, мөгезләр күренмәсен өчен фуражкасын киде. Шуннан стакан белән су алып килеп Саимәнең битенә чәчрәтте.

- Ханым, ханым... Каушамагыз әле шул кадәрле... Мин бит алкоголикларны куркытучы шайтан. Хатын-кызга тимим мин...

Саимә башын калкытты, торып утырды. Аннан сикереп торды һәм чәрелдәп өй почмагына барып сыенды.

- Ханым, мин сезгә тимим, - диде Хатыйп, тавышын мөмкин кадәре йомшартып. - Мин хатын-кыз белән инде күптән шаярмыйм. Карт бит инде мин. Мин эчкечеләрнең котын алучы булып эшлим. Сез Сәлмәннең хатыны буласызмы?

- Әйе, - диде Саимә.

- Сезнең исемегез Саимә инде алайса? Мин Сәлмәннең дусты. Миннән курыкмагыз. Ул миңа фатирының ачкычын калдырып китте.

- Үзе кайда соң ул?

- Шайтан белсенмени аны?... - диде җен. - Ул бу планетадан китеп барды.

Саимә кычкыра башлады:

- Чыгарып җибәрегез мине! Мин монда калырга куркам! Сәлмән! Коткар мине!

Хатыйп чыраен сытты:

- Хатын-кызның шул кычкыру булыр инде аның... Кычкырмагыз, зинһар. Сезгә бит кагылган кеше юк. Сәлмән барыбер ишетмәячәк. Ул хәзер башка планетада яши.

- Нинди планетада?

Җен караватка барып утырды.

- Әйтмим. Алайса сез аны табып, алимент түләттерәчәксез.

- Кайда ул?

- Кайманда!

Саимә, битен чаршау белән каплап, үкси башлады:

- Сәлмән-ә-ән! Кайда син?.. Сәлмә-ә-әне-е-ем!

- "Сәлмәне-е-ем..." - диде җен, үчекләп. - Нәрсә, Сәлмән кирәк булдымыни хәзер? Ташлап чыгып китмәскә иде...

- Бик нык эчте бит... Тузына иде...

- Һе, тузыныр кәнишне... Сап-сары малай табып биргәнсең бит...

- Минем Сәлмәннән башка беркем белән дә булганым юк. Аның баласы ул! - Саимә җенгә таба атлады. - Алып кайт Сәлмәнне монда! Сирәк кенә булса да бала атасын күреп үссен.

- Кызма әле син, Саимә. Ничек алып кайтыйм мин аны? Кәнишне, яшь чагым булса, мин аны күтәреп оча алыр идем дә бит... Юк шул, элеккеге дәрман калмады. Бездә, җеннәрдә, бер әйтем бар: "Яшең җитсә 2040 ка, эшләр китә шырыкка..." Ә миңа инде, аллага шөкер, 2040 кына түгел, 2084 яшь.

Саимә хәлсезләнеп урындыкка утырды.

- Әй, Сәлмән, Сәлмән, - дип пышылдады ул.

Хатыйп аны юатырга тырышты:

- Өзгәләнмә бик, Саимә... Мин сиңа ярдәм иткәләрмен. Чөнки мин гаепле монда...

* * *

Аборигеннар йокларга яткач, Камил Галине төрткәләп уятты.

Галигә бик озак аңлатырга туры килде: Сәлмәннең кем икәнлеген дә, җирдәге хәлләрне дә... Ул Сәлмәнне азат итүгә, өч татар укмашып кыргыйларга каршы торырга каршы килде. Шулай да Камил аны күндерде, чөнки Галинең дә кешеләрчә яшәргә, хәтта берәр вакыт кире җиргә кайтырга да хыялөмете юк түгел иде.

Шулай да Камил Сәлмәнне бәйдән коткарганда ул:

- Зерә мәташабыз, бугай... - дип куйды.

- Юк, юк, зерә түгел, - диде Камил бауны чишәчишә. - Без хәзер өч татар, өч якташ - үзебезчә яшәячәкбез...

Сәлмән аяк-кулларын язылдыргач аңа кыска саплы сөңге тоттырдылар. Нәкъ шул мизгелдә бер кыргый йокысыннан уянып сикереп торды һәм, коралланган татарларны күреп, ачы итеп кычкырып җибәрде.

... Көчләр тигез булу сәбәпле ике як та сугышны башлап җибәрергә батырчылык итмәде. Аборигеннар кычкырып-кычкырып янадылар да, тау артына таба юл тоттылар.

Гали кайгыга батты:

- Алар бездән үч алмый калмаячаклар.

- Әйе, уяу булырга кирәк, - диде Камил, учак янына урнашып.

Азат ителүенә чиксез куанса да, Сәлмән дә уйга чумды:

- Без шулай гомер буе куркып яшәрбезмени?! Теге ләрдән безгә монда рәт булмаячак бит...

- Мондый тормыш та тормыш түгел инде... - диде Камил, таяк белән учакны болгатып. - Җирдә хет, яхшымы-начармы, законнар бар. Ә монда - Билгесезлек.

- Чыннан да, - диде Сәлмән, - закон булмагач, кеше ашаучылардан теләсә нинди кабахәтлек көтәргә була.

Камил мәсхәрәле итеп көлеп куйды.

- Ишетәсеңме, Гали, - диде ул, Сәлмәнгә ымлап. - Үзе җирдәге законнарны сөймичә монда килгән, ә үзе инде бүген үк законнарны сагына башлады.

Гали дә көлеп җибәрде:

- Әле бераз яшәп карасын монда, алимент каеручы хатынын да сагына башлар. Ха-ха-ха! Тагын бераздан җир шарындагы бөтен хатыннарга алимент түләргә дә риза булыр.

- Нишләп монда хатын-кыз заты юк соң? - дип сорап куйды Сәлмән.

- Бар иде алар, - диде Гали, авыр сулап. - Теге кыргыйлар ашап бетерделәр. Хатын-кыз итен бик яраталар.

- Ә җенси мөнәсәбәтләр ничегрәк соң? - дип кызыксынды Сәлмән.

- Аларның берничек тә түгел, - диде Камил. - Печелгәннәр алар. Йолалары шундый. Шуңа күрә, үрчемәгәч, алар өчәү генә калдылар да инде.

(Дәвамы бар).



Ваучер иялəре игътибарына!

Акциянең ни икəнен белəсезме?

Дөрес, бүген акция – хосусыйлаштыру чегын файдалы итеп урнаштыруның бердəнбер реаль юлы.

Россиянең абруйлы компаниялəре, банклары, инвестиция фондларының акциялəрен ваучерга сез бары тик Казан универсаль биржасында гына алмаштыра аласыз.

Без сезне сишəмбе, чəршəмбе һəм пəнҗешəмбе көннəрендə 10 нан 12 гə кадəр көтəбез. Безнең адрес: Казан, Солдатская урамы, 1.

9,14 номерлы трамвай, 1,4 номерлы троллейбус белəн "Энергоинститут" тукталышына кадəр килергə кирəк.

Хосусыйлаштыру чекларын сез көн саен бездə файда белəн сата яки сатып ала аласыз. Биржаның эшлəү вакыты 10.00-12.00 һəм 15.00-17.00 сəгатьлəрдə. Шимбə һəм якшəмбедə: 10.00-12.00.

Элемтəгə керү өчен телефон: 57-84-47.



Өй шартларында ничек итеп көнбагыштан хəлвə ясарга? Əгəр рецепт һəм ничек ясау турында аңлатма кирəк булса, шушы адреска 100 сум акча һəм буш конверт җибəрүегез сорала.

Адрес: 423353, Татарстан, Сарман районы, Дүсел авылы. ХҮ-КБ сериялe, 607365 номерлы паспорт иясенə.

* * *

Колак аппараты өчен электр батареялары сатып алабыз.

Адрес: 422303, Татарстан, Зеленодольск районы, Мулла Иле авылы. Гөлсəгедə НУРИЕВА.

* * *

Мин армиядə бергə хезмəт иткəн Татарстандагы дусларымны эзлим. Алар 1952 елда кайтып киттелəр, ə мин хəрби хезмəттə калдым. Алар – Юнир Хафизов, Госман Яруллин, Җəмил Мөбəрəкҗанов, Иван Васильев. 41 ел вакыт үтсə дə, бəлкем бу белдерүне укып хат язарлар.

Адрес: Башкортостан, Дүртөйле районы, Таймурзино авылы. Авзах ГАЗИЗОВ.

* * *

Яңа төсле телевизорны 48-50 үлчəмдəге тунга яки чəшке бүрегенə алмаштырам.

Телефон: 57-27-47.

* * *

Казаннан бик ерак булмаган татар авылыннан йорт сатып алабыз яки Түбəн Ослангдагы дачага алмаштырабыз.

Телефон: 56-13-76. Р.ГƏРƏФИЕВ.

* * *

Миңа һəм 5 яшьлек улыма бүлəк рəвешендə 150 мең сум акчасын кызганмаган спонсор эзлим.

Адрес: Татарстан, Түбəн Кама шəһəре, Главпочтампт, ХҮІ-КБ серияле, 556114 номерлы паспорт иясенə.

* * *

Башкортостанның Бакалы район үзəгеннəн 9 чакрым ераклыктагы авылдагы өйне яңа җиңел машинага алмаштырам.

Адрес: Башкортостан, Дүртөйле шəһəре, Бакча урамы, 27-33. АЛИЯ.

* * *

Шəхси предприятие түбəндəге кулланма əсбаплар җибəрə: 1. "Тире эшкəртү, мех киемнəр тегү". Бəясе 150 сум. 2. "50 йомыркага исəплəнгəн инкубатор". Бəясе 140 сум. 3. "Колбаса һəм башка ит продуктлары əзерлəү". Бəясе 150 сум. Акча күчерү өчен счет: 715901, Ленинский филиал Башпромбанка г.Уфы, МФО 180737742. Акча күчерү турындагы квитанция белəн адресыгыз язылган конвертны түбəндəге адреска җибəрегез. Заказлар бер атна эчендə башкарыла.

Адрес: 450017, Уфа шəһəре, а/я 407.



Парижның "Зур мода" йортлары эшлəгəн 93 нче ел өчен язгы-җəйге кием-салым коллекциялəрендə яңа аһəң һəм төсмерлəр бик нык сизелə.

Рəсемдə: атластан тегелгəн һəм чəчəклəр белəн бизəлгəн бу күлмəкнең авторы – Лун Феро.

* * *

Япония. Япон аудио-промышленносте чыгарган иң соңгы яңалык – мини-дисклар уйнаткычы. Ул, вакыты җиткəч, гадəти компакт-дискларны алмаштырачак. Мини-дисклар тавышны иң югары сыйфатта яза, секунд эчендə тиешле җырны таба, ə яздырганда иске язмаларны бозмый, ə буш урынны үзе табып, шул урынга яздыра.

Рəсемдə: "Шарп" фирмасының мини-дисклар уйнаткычы. Авырлыгы 290 грамм.

ТАСС фотолары.

Предпритие Казан шəһəрендəге складтан түбəндəге автомобильлəрне сата

ВАЗ - 21063
ВАЗ - 21061
ВАЗ - 21053
ВАЗ - 21083
ВАЗ - 2108

Түлəү тəртибе – телəсə нинди.

Телефоннар: 53-04-94, 53-03-47, 34-13-03.

ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ОРДЕНЛЫ ТАТАР ДƏҮЛƏТ ҖЫР ҺƏМ БИЮ АНСАМБЛЕНƏ 55 ЯШЬ

"БЫЛБЫЛЛЫ ИЛ ТАТАРСТАН"

ЗУР КОНЦЕРТ

Ансамбльнең художество җитəкчесе – Татарстанның һəм Россиянең атказанган сəнгать эшлеклесе Лима КУСТАБАЕВА

27 март — Киров исемендəге культура сараенда. Башлана 19 сəгатьтə.

28 март — Ленин исемендəге культура сараенда. Башлана 18 сəгатьтə.

Билетлар концерт булачак урыннарда сатыла.

Тест * Тест * Тест * Тест * Тест * Тест * Тест

Саклаучы фəрештəгез бармы?

Галим һəм математик, кешенең язмышын да алдан əйтеп бирə белүче Мөхəммəт Ситдыйк Əфган, бик җитди рəвештə, безнең тормышта бер генə очраклы сан да юк, дип белдерде. Аның əйтүенə караганда, машина (хəтта төсе дə), паспорт, фатир, телефон номерына карап та боларның хуҗасы турында ни дə булса əйтергə мөмкин. Туу датасын кулланып (көн, ай, ел) шуны ук үзегез дə тикшереп карый аласыз. Моның фəннилек дəрəҗəсе ничектер, əмма бу – кызыклы.

Шулай итеп, туу датасындагы саннар ни сөйли:

1 – энергияне сез табигатьтəн аласыз;

2 – энергияне кешелəр белəн аралашудан аласыз;

3 – энергия галəмнəн килə;

4 – сəламəтлегегез – тумыштан;

5 – энергияне мəхəббəт бирə;

6 – интуиция (сизгерлек);

7 – саклаучы фəрештə бар дигəн сүз;

8 – язмыш йөртə;

9 – интеллект (көчле акыл).

Əгəр дə туу датасында берничə "1" саны бар икəн, энергия хəттин ашкан дигəн сүз. Сез "янып көлгə əйлəнгəн" җирдəн, инде бер өмет калмады дигəндə дə терелеп күтəрелə торган кеше. "Урынында утырып тора алмый" дигəн сүзлəр нəкъ менə сезнең турыда...

Əгəр дə "4" саны бар икəн – бу – сез бөтенлəй дə чирлəмисез дигəн сүз түгел. Əмма сездəге сəламəтлек иң җитди авыруны да җиңеп чыгарга җитəрлек.

"3" саны хуҗалары – потенциаль экстрасенс һəм дəвалаучылар. Əмма һəр талантны; бары хезмəт һəм үз өстеңдə эшлəп кенə үстереп була.

Əгəр дə сезнең "кулда" "5" саны юк икəн, бу əле бер дə сезгə мəхəббəтнең кирəге юк дигəн сүз түгел. Бу бары тик сезнең төп энергия чыганагы башка нəрсə икəне турында гына сөйли.

Графика • М ждёт вас !



БЕСПЛАТНОЕ ВЫПОЛНЕНИЕ ЭСКИЗОВ И ПОЛУЧЕНИЕ РАЗРЕШЕНИЙ МВД

Мы работаем быстрее и лучше всех !

Великолепные печати и штампы
(на любом языке, любой сложности)
Визитные и деловые карточки, товарные бирки

ЭКСПРЕСС-ЗАКАЗ 6 ЧАСОВ

Разработка товарного знака и фирменного стиля документации Вашего предприятия с последующим выполнением высококачественных макетов фирменных бланков

Продажа импортных канцелярских товаров ✆ 37 76 33

Фирма также осуществляет:

Подбор и продажу очков, оправ и линз ✆ 37 71 39

ПРИЁМ ЗАКАЗОВ:
в раб. дни: с 8 до 18
по субботам: с 8 до 12

ул. ОРЕНБУРГСКИЙ ТРАКТ, 20
проезд троллейбусами 6, 8, 11, 12, до остановки "ВДНХ"



"Йорт" региональ Сəүдə йорты

хосусыйлаштыру объектларын сату буенча аукционның (бу турыда хəбəр "Т.Я."нең 16 март санында басылган иде) 30 мартта Казан финанс-экономика институтының актлар залында сəгать 10да үтəчəге турында белдерə. Аның адресы: Бутлеров урамы, 4 йорт.

Мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз!



Баш мөхəррир Исмəгыйль ШƏРƏФИЕВ (53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2. "Татарстан яшьлəре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхəррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сəркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сəяси тормыш һəм тəрҗемə, фəн һəм мəгариф
53-07-56 - мəдəният-сəнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьлəре"н гамəлгə куючылар – ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьлəр оешмалары советы, Татарстан Мəгълүмат һəм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мəгълүмат һəм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белəн теркəлде.

"Т.Я" сишəмбе, пəнҗешəмбе, шимбə көннəрендə чыга

Редакциягə килгəн материаллар рецензиялəнми һəм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерлəре бу əле редакция фикере дигəн сүз түгел.

Редакциянең исəп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханəсе.   Газета басылуга кул кую график буенча 18 сəгатьтə. Бу санга 14 сəгатьтə кул куелды.   Заказ 6068